ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная , д. 2а, д.Нижние Аты
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урамы, 2а йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)50-7-35, факс (84366)50-7-35 E-mail:Sat.Ars@tatar.ru

# КАРАР

« 31 гыйнварь 2024 ел №1

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Урта Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләре күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җирләү һәм җирләү эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында "Җирләү һәм җирләү эше турында" Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында" 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, "2024 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Урта Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен әлеге карарга 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә билгеләргә һәм 2024 елның 01 февраленнән гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Урта Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында" 2023 елның 02 февралендәге 02 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны үз өстемә алам.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы : Батталова Р.Х

Арча муниципаль районы
Урта Аты авыл җирлеге
башкарма комитетының
31 гыйнварь 2023 ел, №1
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Урта Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5542,29 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 669,33 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2158,58 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |

Арча муниципаль районы
Урта Аты авыл җирлеге
башкарма комитетының
31 гыйнварь 2024 ел, №1
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Урта Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне киендерү | 301,19 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5241,10 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 669,34 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2158,57 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |